**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ БОЕРЫК

02.12.2020 № 677-р

Үзгәрешләр кертү турында

Спорт әзерлеге программасын гамәлгә ашыру һәм муниципаль спорт мәктәпләренең спорт командалары арасында хоккей буенча Татарстан Республикасы Чемпионатында һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе Чемпионатында (А төркеме) катнашуы белән бәйле рәвештә

КАРАР БИРӘМ:

1. «2016-2020 елларга Нурлат муниципаль районында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертергә һәм «2016-2020 елларга Нурлат муниципаль районында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 12 февралендәге 69 номерлы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының карары белән расланган «2016-2020 елларга Нурлат муниципаль районында яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертергә һәм 2 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин

«2016-2020 елларга физик культура һәм спортны үстерү» ярдәмче программасына 2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү кысаларында Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чаралар исемлеге

| Максат | Бурыч | Чаралар атамасы | Ахыргы нәтиҗәләр сыйфатын бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторлар күрсәткече | Еллар | Финанслау еллар буенча, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| Массакүләм спортны популярлаштыру һәм җәмгыятьнең төрле катламнарын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү юлы белән халыкның сәламәтлеген ныгыту өчен | яшәү урыны, уку, хезмәт эшчәнлеге буенча төрле категорияләрдәге һәм төркемдәге физик культура, спорт белән шөгыльләнү өчен уңайлы шартлар формалаштыру | Балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр арасында картинг, милли, хәрби-гамәли спорт төрләре, көнчыгыш көрәш буенча район физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы чаралар үткәрү | Укучыларның һәм студентларның гомуми санынннан физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче укучылар һәм студентлар өлеше, процентлар | 50,2 | 2021 | 13 ,0 | 15,0 | 20,0 | 25,0 | 30,0 |
| | | | | 51,1 | 2022 | | | | | |
| | | | | 52,1 | 2023 | | | | | |
| | | | | 53,3 | 2024 | | | | | |
| | | | | 54,5 | 2025 | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| шартлар тудыру | | | | | | | | | | |
| | | <u>«Күн туп», «Алтын алка» ярышларының район этапларын һәм этапларын уздыру</u> | | | | | | | | |
| | | Спортның уен төрләре буенча халыкның урта һәм өлкән яшь төркемнәре (ветераннар, өлкән яшьтәге затлар) арасында район физкультура-сәламәтләндерү, комплексны чаралар үткәрү. | | | | 20,00 | 25,00 | 30,00 | 35,00 | 40,00 |
| | | «Сәламәтлек» спартакиадасы кысаларында чемпионатлар, беренчелек, ачык район турнирлары, авыл командалары арасында комплексны чаралар үткәрү, авыл командалары арасында ярышлар уздыру | | | | 70,00 | 80,00 | 90,00 | 100,00 | 150,00 |
| | | «Сәламәтлек» спартакиадасы кысаларында төрле спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, ачык турнирлар, барлык милек рәвешендәге предприятиеләрдәге КФХлар арасында комплексны чаралар, гаилә чараларын да кертеп, спортның төрле төрләре буенча ярышлар уздыру | | | | 20,00 | 25,00 | 30,00 | 35,00 | 40,00 |
| | | Физкультурачылар көненә багышланган район физкультура-спорт бәйрәмнәрен, спорт чараларын, бөтенроссия чараларын, «Россия чаңгы юллары», «Милләтләр кроссы» һ. б. уздыру. | | | | 25,00 | 30,00 | 35,00 | 40,00 | 50,00 |
| Балалар-яшүсмерләр спортын һәм югары казанышлар спортын үстерү | Спорт резервын әзерләү | Ведомство карамагындагы спорт корылмаларын карап тоту һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү | | | | | | | | |
| | | Алкалы хоккей буенча «Ледок» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә алкалы хоккей буенча балалар-яшүсмерләр спортын үстерү | | | | | | | | 482,400 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Югары класслы спортчылар әзерләү | Спорт төрләре буенча район, зона, республика, бөтенроссия ярышларын уздыру | | | | 110,00 | 120,00 | 150,00 | 160,00 | 200,00 |
| | | Районның әйдәп баручы спортчыларына һәм тренерларына дәүләт ярдәме | | | | | | | | |
| | | Спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | | | | | | | | 373950 |
| | | Муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан спорт төрләре буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча муниципаль йөкләмәнең спортчыларны йөртү буенча аутсорсинг хезмәт күрсәтүләренә бәйле чыгымнар өлешендә үтәлешен финанс белән тәэмин итү максатларында субсидияләр бирү | | | | | | | | 158,26 |
| | | «Демография» милли проектының «Спорт-тормыш нормасы» федераль проектын гамәлгә ашыру, Нурлат муниципаль районының матди-техник базасын ныгыту | | | | | | | | 2732,955 |